**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Бала туу һәм аны тәрбияләп үстерү белән бәйле айлык акчалата пособие турында**

«Балалы гражданнарга дәүләт пособиеләре турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 21 ноябрендәге 455-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителү белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. 2023 елның 1 гыйнварыннан «Балалы гражданнарга дәүләт пособиеләре турында» 1995 елның 19 маендагы 81-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә билгеләнгән бала туу һәм аны тәрбияләп үстерү белән бәйле айлык акчалата пособие (алга таба тиешенчә – айлык пособие, Федераль закон) билгеләү һәм түләү буенча Татарстан Республикасы вәкаләтләрен Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фондына тапшырырга.

2. Айлык пособие Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бала туу һәм аны тәрбияләп үстерү белән бәйле айлык акчалата пособие билгеләү һәм түләү тәртибе турында» 2022 елның 16 декабрендәге 2330 номерлы карары (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәте карары) нигезендә башкарыла дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фонды белән әлеге Указның 1 пункты нигезендә тапшырылган Татарстан Республикасы вәкаләтләрен үтәү өчен Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фонды бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан субвенция бирү турында килешү төзергә;

2023 елның 1 гыйнварына кадәр «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе аша яисә «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләре) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып гражданнарның айлык пособие билгеләү турында мөрәҗәгатьләрен, шул исәптән гражданнардан дәүләт хезмәте күрсәтә торган органнар, муниципаль хезмәт күрсәтә торган органнар, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары карамагындагы

оешмалардан документларны таләп итмичә, кабул итү мөмкинлеген тәэмин итәргә;

2023 елдан башлап ел саен Россия Федерациясе субъектлары бюджетына федераль бюджеттан субсидияләр формалаштыру, бирү һәм бүлү тәртибе нигезендә Россия Федерациясе субъектларының айлык пособие түләүгә чыгым йөкләмәләрен уртак финанслау күләмен исәпкә алып, Татарстан Республикасы бюджетыннан Федераль законны үтәү белән бәйле чыгымнарны финанслауга бюджет ассигнованиеләре бүлеп бирүне күздә тотарга;

Россия Федерациясе Хөкүмәте карарын һәм әлеге Указны үтәү өчен кирәкле башка карарлар кабул итәргә.

4. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Президентының «Өч яшьтән алып җиде яше тулган балаларга айлык акчалата түләү турында» 2020 елның 8 апрелендәге ПУ-227 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында Россия Федерациясе Президентының «Балалы гаиләләргә айлык акчалата түләү турында» 2022 елның 31 мартындагы 175 номерлы Указын гамәлгә ашыру чаралары турында» 2022 елның 16 апрелендәге ПУ-285 номерлы Указы.

5. Әлеге Указ, әлеге Указның аңа кул куйган көннән үз көченә керәчәк 3 пунктыннан кала, 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә кертә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2022 ел, 23 декабрь
№ ПУ-908